РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

25.07.2025_ №575-п

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә урнашкан балалар уен һәм спорт мәйданчыкларын тикшерү буенча комиссия төзү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль закон, 2004 елның 29 декабрендәге 188-ФЗ номерлы “Россия Федерациясе Торак кодексы” Федераль законына һәм “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына нигезләнеп, шулай ук Саба муниципаль районы территориясендә балаларның уен һәм спорт мәйданчыкларында иминлекләрен тәэмин итү максатларында Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә урнашкан балалар уен һәм спорт мәйданчыкларын тикшерү буенча комиссия төзергә һәм аның составын расларга (1 нче кушымта).

2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә урнашкан балалар уен һәм спорт мәйданчыкларын тикшерү комиссиясе эшчәнлеге тәртибе турындагы Нигезләмәне расларга (2 нче кушымта).

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Саба муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы Э.Д. Рамазановка йөкләргә.

Җитәкче М.Р. Ишниязов

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Башкарма комитетының

____________карарына

1нче кушымта

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә урнашкан балалар уен һәм спорт мәйданчыкларын тикшерү комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Ишниязов М.Р. | Саба муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе |
| Рамазанов Э.Д. | Саба муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы, комиссия рәисе урынбасары |
| Рәхмәтуллин В.Н. | Саба муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге баш белгече, комиссия сәркатибе |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Гарипов И.Р. | Саба муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге башлыгы |
| Галиуллин А.М. | Саба муниципаль районының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре Палатасы рәисе |
| Шакиров И.Ф. | «Саба муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы |
| Җирлек башлыклары | Мәйданчыкның урнашу урыны буенча |

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Башкарма комитетының

____________карарына

2нче кушымта

## Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә урнашкан балалар уен һәм спорт мәйданчыкларын тикшерү комиссиясе эшчәнлеге тәртибе турында Нигезләмә

### I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә урнашкан балалар уен һәм спорт мәйданчыкларын тикшерү комиссиясе (алга таба - Комиссия) балалар һәм яшүсмерләр мәйданчыкларында (уен, спорт мәйданчыкларында) балалар һәм яшүсмерләр тормышына һәм сәламәтлегенә авыр нәтиҗәләргә, имгәнүләр китереп чыгарырга мөмкин булган сәбәпләрне һәм шартларны бетерүгә, эксплуатацияләүдә куркынычсызлык буенча контрольне тәэмин итүгә, шулай ук уен җиһазларының техник торышын иминлек таләпләренә туры килүен бәяләүгә юнәлдерелгән эшләр уздыру максатыннан төзелә

1.2. Комиссия эшендә әлеге Нигезләмәгә, барлык төр җиһазларны монтажлаганда һәм эксплуатацияләгәндә иминлекнең гомуми таләпләрен билгели торган норматив документларга таянып эш итә.

1.3. Комиссия Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә урнашкан балалар уен һәм спорт мәйданчыкларындагы җиһазларга тикшерү уткәрә.

### II. Комиссиянең бурычлары

Комиссиянең бурычлары түбәндәгеләр:

2.1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә урнашкан балалар уен һәм спорт мәйданчыкларында җиһазларны, куркынычсызлыкның төп таләпләрен исәпкә алып, дәүләт стандартларына туры китерү буенча тикшерү үткәрү.

2.2. Балалар һәм яшүсмерләрнең гомере өзелү, имгәнү һәм сәламәтлегенә авыр нәтиҗәләр китереп чыгаручы сәбәпләрне бетерү буенча тәкъдимнәр әзерләү.

### III. Комиссия вәкаләтләре

3.1. Комиссия уен җиһазларын (аның техник халәтен, конструкциянең бөтенлеген, эретеп ябыштыру җөйләренең торышын, беркетү урыннарын һәм

беркетелгән детальләрнең торышын, җайланманың ышанычлылыгын, лак буяу өслекләренең сыйфатын, габаритлы үлчәмнәрне һәм тышкы кыяфәтен карауны) комплекслы тикшерә.

IV. Комиссиянең составы һәм аны төзү тәртибе

4.1. Комиссиянең тубәндәге составта төзелә: Комиссия рәисе, Комиссия рәисе урынбасары, сәркатибе һәм Комиссия әгъзалары.

4.2. Комиссия әгъзалары Комиссия эшчәнлегенә кагылышлы булган документлар һәм материаллар белән танышырга хокуклы.

V. Комиссия эшен оештыру

5.1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә урнашкан балалар уен һәм спорт мәйданчыкларының җиһазларын еллык төп карап чыгу.

Еллык төп карау елга бер тапкыр, 1 нче майдан да соңга калмыйча, җиһазларның техник торышының куркынычсызлык таләпләренә туры килүен бәяләү максатыннан үткәрелә.

Ел саен төп карау барышында түбәндәгеләр билгеләнә:

- балалар мәйданчыгы (уен, спорт, ишегалды) һәм җиһазлар өслегенең чисталыгы һәм тышкы кыяфәте;

- җиһазлар өлешләреннән уен мәйданчыгы өслегенә кадәр булган ераклыкларның утәлешен саклау;

- фундаментларның чыгып торган өлешләре булу;

- җиһаз элементларының дефектлары/төзексезлеге булу;

- җиһазларның детальләре булмау;

- җиһазларның хәрәкәтчән өлешләренең кирәгеннән артык тузуы;

- җиһазларның структур бөтенлеге;

- агач элементларда черек өлешләр булу;

- металл элементларның коррозиясе булу;

- башкарылган ремонт эшләренең җиһазлар иминлегенә йогынтысы.

Җиһазларның яшерен, авыр үтеп керә алырлык элементларына аерым игътибар бирәлә.

5.2. Тикшерү тәмамланганнан соң Комиссия Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә урнашкан балалар уен һәм спорт

мәйданчыкларының җиһазларын карау һәм тикшерү актын әзерли (әлеге Нигезләмәгә кушымта).

Балалар уен һәм спорт мәйданчыгын карау акты тикшерү үткәрелгән көннән алып 5 (биш) эш көне эчендә рәсмиләштерелә.

Балалар уен һәм спорт мәйданчыгын карау акты 1 нөсхәдә рәсмиләштерелә, ул Саба муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлегендә саклана.

5.3. Тикшерү барышында уен һәм спорт җиһазларының имгәнүләр һәм зыян китерергә мөмкин булган куркынычсызлык таләпләренә туры килмәве ачыкланганда, Комиссия кичекмәстән спорт яисә уен җиһазларын куллануны туктатып тору, ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү яисә төзек булмаган җиһазларны сүтеп кору чараларын күрә.

Төзек булмаган җиһаздан файдалануны туктатып тору йә аны киртәләү юлы белән, йә әлеге җиһазның файдалану өчен куркыныч булуы турындагы мәгълүматны урнаштырып, әйләндереп алу юлы белән гамәлгә ашырыла.

Комиссия тарафыннан ачыкланган хокук бозуларны һәм туры килмәүләрне бетерү өчен шәһәр (авыл) җирлеге җитәкчесенә 7 көнлек срок бирелә, шул вакыт узганнан соң комиссия мәйданчыкны тагын карый һәм Нигезләмәнең 5.2 пункты нигезендә кабат карау акты чыгара.

Хокук бозулар төзәтмәгән очракта, комиссия кабат тикшерү акты төзелгән вакыттан алып 3 көн эчендә аның күчермәсен гаепле затны административ җаваплылыкка тарту өчен АТИ га җибәрә.

5.4. Комиссия кабул иткән бәяләмә белән килешмәгән әгъзалар үзләренең аерым фикерен язма рәвештә бәян итәргә хокуклы, ул Комиссия бәяләмәсенә кушымта итеп бирелә.

5.5. Комиссия карарлар кабул итү өчен билгеләнгән компетентлык чикләрендә һәм гамәлдәге законнар нигезендә җаваплылык тота.

Татарстан Республикасы С
аба муниципаль ра
йоны территориясендә урнашкан балалар уен һәм сп
орт мәйданчыкларын тикшерү комиссияс
енең эш тәртибе турында нигезләмәгә кушымт
а

Балалар уен, спорт мәйданчыгын карау, тикшерү АКТы

"____"_____________ 20_____________

Комиссия составы:

(вазыйфасы, фамилиясе, инициаллары)

(вазыйфасы, фамилиясе, инициаллары)

(вазыйфасы, фамилиясе, инициаллары)

(вазыйфасы, фамилиясе, инициаллары)

_______________________________________________________ адресы буенча урнашкан балалар уен, спорт мәйданчыгына визуаль тикшерү уздырдым:

Тикшерү вакытында түбәндәгеләр ачыкланды:

| т/б № | Җиһазлар аталышы | Тикшерү нәтиҗәсе | Ачыкланган дефект |
|---|---|---|---|

Комиссия бәяләмәсе

Имзалар:

_____________________________________

_____________________________________

______________________________________